

18 март – Сәvдә, халыкка конкvреш хезмәте кvрсәтv һәм торак-коммуналь хужалык хезмәткәрләре коне. Безнен һәр конебез бу олкә хезмәткәрләре белән бәйле. Торак-коммуналь хужалык – торак пунктларнын яшәешен тәэмин итvче катлаулы система. Менләгән кешенен кәефе әлеге тармак эшчәнлегенә бәйле. Гомумән, һәр кешенен фатиры, социаль объектлар жылы, якты, унайлы булсын очен торак-коммуналь тармак хезмәткәрләреннән уяу эшләv сорала. Домоуправление, ТСЖ  хезмәткәрләре очен ел буеннан-буена мәшәкатьләрдә уза. Ә кыш белән яз очрашкан чор аерата катлаулы: карын да чистартасы, язына да әзерләнәсе бар.
Ойләребездә я кранибыз ватылса, я кыш коне тиешле дәрәжәдә жылылык белән тәэмин ителмәсә, тиз тиешле урынга шалтыратып минут эчендә барысын тозәтеп, эшләп бирvне таләп итәбез. Аларны еш сvгәбез; бар араларында эшләренә салкын карауучылар. Барысын да бер тарак белән тарарга кирәкмәс дип уйлыйм. Шулай, кvршем Саниянен туалеты стоягы турысыннан сары су ага башлагач, тиз генә vзебезгә тиешле ярдәм кvрсәтvче Саранск шәһәре № 31 Домоуправлениесе номерына шалтыратканы турында әйтте. Белгечләр тиз генә килеп, анын мәсьәләсен чишv очен, стоягын караган. Хыял аларнын остендә яшәгән квартирда дип оскә шалтыраткан мастер. Ишек ачучы булмагач, янә эш урынына кайтып киткән. Бераз сары су аккач, vзеннән-vзе тукталган да тагын.Татар кешесе чисталыкны, похтәлекне ярата, кvршем стоягын краскалап та куярга олгергән. Вакыты-вакыты белән тагы сары су аккалаган, Сания янә 31 участокка барып директоры Нина Николаевна Буяновага морәжәгать иткән. Ул бу олкәдә утыз биш ел хезмәт итә торган белгеч. Сораштыргач, vзе ук булган хыялнын сәбәбен әйтеп биргән. Мастерына инструктаж биреп заявканы vтәргә жибәрергә ышандырган. Саниям vзенен алдында олы яшьтәге картнын гафре тотып Нина Николаевнага соравын юнәлдергән: “Сез генә мина ярдәм итә аласыз...»  Бар кешене тынлый белгән, проблемаларны конструктив чишкән житәкчеләр бу олкәдә бик аз алар. Әмма шундыйларны ишеткәч, кvргәч, кvнелдә ниндидер тынычлык урнаша. Мин дә аны кvрергә теләдем. Очраштык. Молләем ханым: “Безнен эш шәһәр территориясендәге юллар һәм тротуарларны жыештырудан гына тормый. Әлбәттә инде, безгә урамнарыбызнын торышына карап бәя

бирәләр. Топ вазыйфабыз  – торакларда кышка әзерлек (мәсәлән, жылы транспортлау магистралендә гидравлик сынау vткәрv, объектларнын барысында да диярлек жылыту системалары басым астында сынап караулар...), яз башы килеп житкәч-жәйгә әзерлек эшләрен алып барабыз, - дип сойләде Саранскнын  31нче Домуправление директоры Нина Николаевна Буянова. - Проблемалар дигәч, алар һәрвакыт житәрлек. 27нче февральдә жылылык трассабыз ватылып (трассага 30 ел!), Ярославская, Волгоградская, Косарева урамындагы 158 йортта, дvрт социаль объектта 15 мен кеше жылысыз утырды. Шәһәр администрациясе һәм министрлык ярдәме белән иртән ватылган объекттан кичке сигез сәгатьтә жылылыкны квартирларга жибәрдек тә, кыш бит! Менә зур дигәннәре, алар еш булып тормый, ә ваклары – чvпләп бетергесез; барысын унай якка хәл итәсе килә, әмма һәрвакыт барысын да гел вакытында башкарып булмый. Сәбәпләре дә торле; я материал булмый, я тиешле белгеч булмый...”
Бу олкәдә дә эшлисе эшләр житәрлек. Әмма бәйрәмнәре унаеннан торак-коммуналь хезмәте алдынгыларын котлап унышлар телибез. Шул исәптән, Нина Николаевнага да һәр кешенен фатирын, социаль объектларны жылы, якты, унайлы булсын очен торак-коммуналь тармак хезмәткәрләреннән уяу эшләvне таләп итvе очен рәхмәтлебез.

**Н.Хәлил**